РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
СОРОК-САЙДАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫРЫК САДАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«19» февраль 2021 ел № 1-15

Карар үз көчен югалткан дип
тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 3 декабрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерүгә китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау хакында» карары нигезендә Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлеге советы,

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Кырык Садак авыл җирлеге Советының 2011 елның 30 апрелендәге 1-10 номерлы «Яктырту приборлары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы Кырык Садак
авыл җирлеге башлыгы В.Ф. Шаһиева